**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

| | | |
|---|---|---|
| Сарлы авылы | № 111-56 | 09 октябрь, 2018 ел |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2011 елның 02 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең муниципаль милектәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы норматив хокукый актларын «Конкуренцияне яклау турында»гы 2018 елның 04 июнендәге №135-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында

Сарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2011 елның 02 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең муниципаль милектәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 3.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән конкурс яисә аукцион нәтиҗәләре буенча дәүләт яисә муниципаль контракт төзелгән затка, әгәр күрсәтелгән хокукларны әлеге дәүләт яисә муниципаль контрактны үтәү максатларында аукцион турында документлар, документация белән каралган булса, яисә дәүләт яисә муниципаль автоном учреждениесе белән конкурс яки аукцион нәтиҗәләре буенча «Юридик затларның аерым төрләренең товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкалары турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән шартнамә яисә аукцион төзегән затка, әгәр күрсәтелгән хокукларны әлеге шартнамәне үтәү өчен документация сатып алу максатлары каралган булса. Мондый мөлкәткә күрсәтелгән хокукларны бирү срогы дәүләт яисә муниципаль контрактны йә шартнамәне башкару срогыннан артмаска тиеш;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.Р.Шәрипов